ГЛАВА ЗАИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

21.08.2026 г.Заинск № 140

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Яңа Спас авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелешләр Кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законы, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2026 елның 21 августындагы 01-09-20099. номерлы хаты нигезендә

**карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Яңа Спас авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләргә.
2. Гавами тыңлауларны оештыручы составын-коллегиаль киңәшмә органын расларга:
1) Уразайкин П.С. – Зәй муниципаль районы Башлыгы урынбасары;
2) Усик О.В. - Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге баш белгече, гавами тыңлаулар секретаре;
3) Әгъләмов Р.В. - «Җир төзелеше бюросы" ҖЧҖ директоры (килешү буенча);
4) Кудряшов В.В. - Зәй муниципаль районы Советының юридик бүлеге башлыгы (килешү буенча);
5) Камалиев Ф.Т. - Зәй муниципаль районында авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы (килешү буенча);
6) Шакиров И.Н. - Зәй шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча);
7) Оборина Г.Ф. – Зәй муниципаль районы мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасы рәисе вазифаларын башкаручы (килешү буенча).
3. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетына гавами тыңлауларны оештыручыга җирле үзидарә, шәһәр төзелеше эшчәнлеге

4. турындагы кануннар нигезендә гавами тыңлауларны оештыруны һәм уздыруны тәэмин итәргә.
5. Гавами тыңлаулар үткәрү 2026 елның 21 сентябреннән да соңга калмыйча тәмамланырга тиешлеген билгеләргә.
6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга.
7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Зәй муниципаль районы**
**Башлыгы вазифаларын башкаручы** **П.С. Уразайкин**